КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 17 июль г.Казань № 839

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 5 ноябрь, 845 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирә торган белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнарны кабул итүнең контроль саннарын бүлүгә конкурс үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирә торган белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнарны кабул итүнең контроль саннарын бүлүгә конкурс үткәрү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 15 гыйнвар, 6 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 декабрь, 1071 нче; 2016 ел, 27 сентябрь, 684 нче; 2017 ел, 19 август, 592 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме

һәм югары белем бирә торган белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнарны кабул итүнең контроль саннарын бүлүгә конкурс үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин